проект

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Законы

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), «дүрт елга» сүзләрен «алты елга» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Россия Федерациясендә судьялар бергәлеге органнары турында» Федераль законның 6 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 2 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре вәкаләтләре, әгәр аларның срогы күрсәтелгән Федераль закон гамәлгә кергән көнгә бетмәгән булса, ике елга озайтыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын үстерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясендә судьялар бергәлеге органнары турында» Федераль законның 6 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 2 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләрдә каралганча, судьялар бергәлегенең кайбер органнары сайланып куела торган сроклар дүрт елдан алты елга кадәр озайтылган.

Моңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә закон проекты белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

Моннан тыш, 2026 елның 2 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлеше нигезендә закон проектында Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре вәкаләтләре, әгәр аларның срогы күрсәтелгән Федераль закон гамәлгә кергән көнгә бетмәгән булса, ике елга озайтыла, дип билгеләнгән.

Закон проекты 2 статьядан гыйбарәт. Закон проектының 2 статьясында законның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүе каралган.

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисәкабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергәе яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә аларны кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.